РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Нижнекуюкского
сельского поселения
Атнинского муниципального
района
ул. Татарстан, д.71а, с.
Нижний Куюк, 422741
Тел. (8843)69-3-32-47, 3-32-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл жирлеге
башкарма комитеты

Татарстан урамы, 71а, Түбән Көек
авылы, 422741
Тел. (8843)69-3-32-47, 3-32-47

---

“17” август 2022 ел. № 15

# КАРАР

Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Түбән Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында " 2020 елның 25 мартындагы 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 нче номерлы " Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" гы карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән ) нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 25 мартындагы 4 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Түбән Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана”;

1.2. 12 пунктның 2 абзацында "дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементлары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.